ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ
2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Караталга авыл җирлегендә үзара салым кертү турында

2022 елның 8 декабре, № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлегенең Караталга торак пунктында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлегенең Караталга торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) торак пунктта юл-урам челтәрен төзекләндерү һәм зиратка кадәр юл (сатып алу, ташу, таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
2) юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
3) җәйге вакытта территорияне чаптыру (КРН-2,1 ротация чапкычының запас өлешләрен сатып алу, ягулык-майлау материалларын сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
4) торак пункт территорияләрен төзекләндерү (агачларны кисү һәм складлау урынына чыгару, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
5) янгын гидрантларын тоту (янгын краннарын, җайланмаларны әзерләү) кышка - җылыту, люкларны кардан, боздан даими чистарту, язгы-җәйге янгын куркынычы чорына тикшерү һәм әзерләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
6) ял итү зонасын булдыру эшләрен башкару (чыгымнарны түләү, газон сатып алу һәм чәчү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

РИЗА КАРШЫ

3. Әлеге карарны Иске Казиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://kamskoye-ustye.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Казиле авыл җирлеге башлыгы
Кама Тамагы муниципаль районы ___________________________и. Х. Сәгъдиев